**Республика Татарстан**
**САРМАНОВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ**
**РАЙОН**
**САКЛОВ-БАШСКОЕ**
**СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ**
ул. Ленина, д. 93 а,
с. Саклов-Баш, 423373.
Телефон: (85559) 4-33-38
E-mail: Sakb.   ar@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**САРМАН**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**САКЛАУБАШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
Ленин урамы, 93 а йорт,
Саклаубаш авылы, 423373.
Телефон: (85559) 4-33-38
E-mail: Sakb.Sar@tatar.ru

ОГРН 1061687003003 ИНН/КПП 1636005510/163601001 ОКАТО 92253856000

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.04.2021 № 7

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 гыйнварындагы 1 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче кушымтада «Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү» юлында хезмәтләр бәясен (сумнарда) 3700,0 ны 3700,80 гә алмаштырырга һәм аны яңа редакциядә әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (sarmanovo.tatarstan.ru) урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Саклаубаш авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Л.М.Габидуллина

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге
башкарма комитетының
09.04.2021 елның 7 номерлы
карарына кушымта
(29.01.2021 ел,
№ 1 карар редакциясендә)

2021 елның 29 гыйнварыннан җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәяләре

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәяләре (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3700,80 |
| 3.Мәрхүмнең гәүдәсен (гәүдә өлешләрен) зиратка күчерү | 1336,39 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1387,79 |
| Барлыгы | 6424,98 |